ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 июль, 2026 ел № 8/8

Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 47, 56 статьялары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11, 2019 елның 25 февралендәге 30/6, 2019 елның 1 августындагы 32/11, 2020 елның 17 июнендәге 40/6, 2021 елның 18 мартындагы 6/12, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/9, 2022 елның 23 июнендәге 15/10, 2023 елның 29 июнендәге 25/10, 2024 елның 30 октябрендәге 37/11 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 9.14 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) реклама-мәгълүмат материалларын яшел утыртмаларга (агачларга, куакларга һ. б.), су агызу торбаларына, урам киртәләренә, асфальт һәм плитка өслекләренә һәм бу максатлар өчен билгеләнмәгән башка урыннарга урнаштыру һәм алардан файдалану;»;

2) 120 пунктның 1 пунктчасын көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев